ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
КАРАКАШЛИНСКОГО СЕЛЬСКОГО
ПОСЕЛЕНИЯ ЮТАЗИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул.Мирфатиха Закиева, д.47,
с.Каракашлы, 423961

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЮТАЗЫ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ КӘРӘКӘШЛЕ АВЫЛ
ҖИРЛЕГЕ БАШКАРМА
КОМИТЕТЫ
Мирфатыйх Зәкиев урамы, 47йорт,
Кәрәкәшле авылы, 423961

Тел.:(85593) 4-21-34, факс:4-21-21, e-mail: Karak.Utz@tatar.ru

**П О С Т А Н О В Л Е Н И Е** **КАРАР**

30.01.2024 ел Кәрәкәшле ав. № 6

**2024, 2025, 2026, 2027, 2028 елларга шәхси ярдәмче хуҗалыкларны исәпкә алуның яңа хуҗалык буенча китапларын булдыру һәм алып бару турында**

2003 елның 7 июлендәге «Шәхси ярдәмче хуҗалык турында»гы 112-ФЗ санлы Федераль законның 8 маддәсе, 2003 елның 6 октябрендәге «Җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында»гы 131-ФЗ санлы Россия Федерациясе Федераль законы, 2022 елның 27 сентябрендәге «Хуҗалык китапларын алып бару формасын һәм тәртибен раслау хакында»гы 629 санлы Россия Федерациясе Авыл хуҗалыгы министрлыгы боерыгы нигезендә һәм Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Кәрәкәшле авыл җирлеге территориясендә шәхси ярдәмче хуҗалыкларны исәпкә алу максатларында, Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Кәрәкәшле авыл җирлеге башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Кәрәкәшле авыл җирлеге территориясендә шәхси ярдәмче хуҗалыкларны исәпкә алуның яңа хуҗалык китапларын, 2024-2028 елларга электрон формада, авыл хуҗалыгы товар җитештерүчеләренең бухгалтерлык һәм махсуслаштырылган хисапларын җыю һәм эшкәртүнең комплекслы мәгълүмати системасын кулланып, җыелма хисаплар, мониторинг, исәпкә алуны формалаштыруны оештырырга, агросәнәгать комплексына ярдәм итүгә субсидияләрне контрольдә тоту һәм анализлауны оештырырга.
2. Һәр ел саен, 1 гыйнварга шәхси ярдәмче хуҗалыкларны тулаем урап узу һәм шәхси ярдәмче хуҗалык әгъзаларыннан сораштыру юлы белән 10 гыйнвардан 15 февральгә кадәр китапларда күрсәтелгән мәгълүматларны җыюны гамәлгә ашырырга.
3. Хуҗалык китапларына язмаларны шәхси ярдәмче хуҗалык башлыгы яки шәхси ярдәмче хуҗалыкның башка әгъзалары тарафыннан ирекле нигездә бирелгән мәгълүматлар нигезендә ясарга.Хуҗалык китапларын алып барганда хуҗалыкны алып баручы гражданнар биргән мәгълүматның конфиденциальлеген, аның саклануын һәм Россия Федерациясе законнары нигезендә яклауны тәэмин итәргә кирәк.
4. Хуҗалык китапларын билгеләнгән тәртиптә алып бару һәм аларның саклануы өчен җаваплы итеп Кәрәкәшле авыл җирлеге башлыгын билгеләргә.
5. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.

7. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

Кәрәкәшле авыл җирлеге башлыгы А.Г.Дәүләтгәрәев